# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* — *№ 6. Январь, 2024 ел*

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА
2023
УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

## Укытучы һәм остаз елы тәмамлана

## Минә ул - чын укытучы!



Һәр көн иртән, кош кебек канатланып, житез адымнар белән һәркемнең игътибарын үзенә җәлеп итеп, башка авылдан килуенә карамастан гел шат, барысына да өлгерүче ханым ишектән килеп керүгә, күңелдә жылы хисләр ташкыны уяна. Әйтерсең, ул ишектән биеп килеп керә, көне буе җинел генә эшли, барысына өлгерә, ул тормыштада шундый, ихлас күңелле, бик уңай кеше, минемчә. Чөнки ул кечкенәдән биергә ярата, мәктәптә дә бии, Казанда университетта укыганда “Каз канаты” халык бию ансамбленә йөри, хәтта Мәскәү сәхнәсендә чыгыш ясый. Аның биюгә осталыгы, тормышында да ярдәм итә. Бик оста биюче булуына карамастан, ул укытучы һөнәрен сайлый. Әтисе юлыннан китә. Әйтергә кирәк, ул бу һөнәрне сайлап ялгышмый. Ул бәхетен балаларга белем бирүдә таба. Бу матур, жылы фикерләрем хезмәттәшем, мәктәбебезнең иң мөлаем, иң дәрәҗәле укытучысы Батршина Сания Фәрит кызы хакында.

Кеше җиргә үз бәхете белән туа, диләр. Сания Фәрит кызының бәхете - укытучы булып эшләвендә, яраткан хезмәтеннән тәм табуында. Үз һөнәренә мөкиббән киткән укытучы ул. Рус теле һәм әдәбияты фәненең бөтен нечкәлекләрен, тәмен тоеп укыта, укучыларына рус әдәбиятының матур үрнәкләрен житкерә, яраттыра, аларның уңышларына эти-әниләр белән бергәләп сөенә белә. 42 ел дәвамында ул балаларга рус теле һәм әдәбиятыннан төпле белем бирә. Ул яхшы белемле, югары эрудициягә ия, бик иҗади шәхес. Аның белеме укучыларында чагылыш таба. Ничә ел инде Сания Фәрит кызы әзерләгән укучылар төрле олимпиадаларда җиңүче, БДИ ны югары баллга бирүче укучылар. Нинди генә бәйге, чара булмасын аның укучылары беренче.

Сания Фәрит кызы - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының, район мәгариф идарәсе, күптөрле балалар иҗат йортларының рәхмәт хатлары, дипломнары, сертификатлары һәм төрле мактаулы исемнәр иясе. Хезмәт юлында бик күп дәрәҗәләргә һәм мактауга лаек булган хезмәттәшем.

Мин аны 35 еллар чамасы беләм. Күлле Киме мәктәбендә белем биргәндә үк аның белән таныш идем. Ул укытучы буларак та, кеше буларак та бик ярдәмчел. Мәктәбебезгә килеп укыта башлагач, мин моның шулай булуына тагын бер кат инандым. Ул туры сүзле, бервакытта да кеше аркылы сүз йөртми, үзенә әйтә. Дөрес булмаса дөресли, аңлата, юл күрсәтә. Мин Аны бик хөрмәт итәм һәм гомумән, аңа сокланам. Тагын бер сокландыргыч өлкә – аның гөлләр үстерүе. Кабинетына килеп керүгә төрле төстә, шау чәчәктә утырган гөлләрне күреп, күзләр камаша. Декабрь аенда да аның гөлләре гөрләтеп чәчәк атып утыра. Аларның савытлары кулдан ясалган. Надир әфәнденең хезмәте. Алар бер берсен тулыландыра. Икесе дә матурлыкка омтыла. Бергә төшкән фотоларын карауга аларның иң бәхетле гаилә икәненә күз төшә. Икесе дә тәрбияле, чын укытучы кешеләр алар. Оясында ни күрсә, кош баласы шуны эшләр ди, халык. Балаларының шулкадәр итагатьле булулары – укытучы гаиләсендә дөрес тәрбия алып үскәнлекләрен күрсәтеп тора. Сания Фаритовнаның бервакытта күңелсезләнеп, ачуланып йөргәнен күргәнем юк. Ул гел елмая. Кызы үзе кебек ачык йөзле, йөзе елмая, үзе елмая. Әнисе кебек оста биюче. Аның белән очрашырга туры килгәне бар. Хезмәттәшем белән нинди генә темага сөйләшсәң дә була. Төрле өлкәләрдә ул безгә остаз. Сыйныф житәкчесе буларак та мин аңа бик күп тапкырлар мөрәҗәгать иттем, төрле ситуацияләрне хәл итүдә ярдәм күрсәтте.

Гомумән, Сания Фәрит кызы - тырыш, гүзәллеккә омтылучы, көчле ихтыярлы кеше. Ул нинди генә эшкә тотынмасын - дәрес бирүме, бәйгеләрдә катнашумы, ата-аналар белән эшләүме, утырышларда чыгыш ясаумы - аларның барысын да хатын-кызга хас булган зәвыклылык, самимилек, игътибар, таләпчәнлек белән башкарып чыга. Аның һәр эше төгәллек, сабырлык, йомшаклык һәм миһербанлылык белән сугарылган була.

Сания Фаритовна! Жир йөзендәге иң изге, иң матур теләкләрне житкереп, кайгы –хәсрәтсез озын гомер, нык сәламәтлек, күтәренке рух, бәхет – куанычлар, күңел тынычлыгы белән Надир әфәнденең канаты астында иркә тормыш иптәше, яраткан әни, назлы дәү әни булып яшәргә язсын. Укучыларыгызны, хезмәттәшләрегезне тагын да куандырып, озак еллар бергә хезмәт итәргә насыйп булсын Сезгә.

**Сөнгатова Гөлнара тарих, татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

## Волонтерлык ул – активлык дәрәҗәсе

Безнең яңашәдә тормышта кешелеклелек сыйфатларын югары куючы, үз эшләренә җаваплы караучы, фидакарь кешеләр күп. Аларны аерып күрсәтергә мөмкин. Ярдәм кулы сузып, җылы сүз әйтүчеләр, башкаларның хәленә керүчеләр алар. Сүзем волонтерлар турында. Волонтёрлар – иң элек, битараф булмаган,игелекле кешеләр дияр идем.Алар еш кына иң авыр вакытларда ярдәмгә киләләр, мондый ярдәм волонтёрлык дип атала. Бөтен кеше дә волонтёр була аламы соң? Әлбәттә... Моның өчен һәр кешедә чын күңелдән ярдәм итү теләге һәм җаваплылык беренче урында булырга тиеш.

Волонтерлык хәрәкәтләре елдан-ел үсә. Аларның республикабызда һәм гомумән, илебездә үткән чаралардагы роле зур.Соңгы елларда республикада таралган коронавирус инфекциясе нәтиҗәсендә ярдәмчесез калган өлкәннәргә, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә, ялгызларга волонтерларның күрсәткән ярдәмнәрен ассызыклап үтәргә мөмкин.Кибеттән кирәкле продукцияләрне, аптекалардан кирәкле даруларны алып китереп бирү аларның төп вазыйфаларының берсе булып торды.

Бүгенге көндә волонтерлык эше тагын да активрак рәвештә күренә башлады. Мобилизация турында бүген белмәгән-ишетмәгән кешеләр юктыр. Күп кешенең туганнары,дуслары, якын кешеләре Украинада барган хәрби операциягә чакырылды. Без алар белән горурланабыз,аларның һәрберсенең исән - сау туган йортларына әйләнеп кайтуларын телибез. Шушы ир-егетләргә беркадәр ярдәм күрсәтү максаты белән безнең Әтнә районында да волонтерлар оешмасы эшләп килә. Алар җылы өс һәм аяк киемнәре, гигиена кирәк яраклары, дарулар, фонарьлар, газ балоннары һәм җылыткычлар, гомумән, егетләргә кулланылышта кирәк булган төрле әйберләрне җыйнап, туплап һәм тәртипләп башка кирәкле таләпләрне дә үтәп ир-егетләргә озаталар. Бу эштә аларга райондагы төрле организацияләр, шул исәптән безнең мәктәп укытучылары һәм укучылары да ярдәм итте.

Меңләгән кеше үз гомерендә бик күп яхшылыклар эшли, чит-ятка да ярдәм итә һәм моның өчен бернәрсә дә сорамый. Яхшылык эшли, игелек кыла, кешелек җәмгыяте каршындагы бурычын үти. Кешелек дөньясында һәрвакыт югары бәяләнгән һәм беркайчанда ярдәмчеллек кыйммәтен югалтмаячак. Яхшы күңелле кешеләр күбрәк булсын инде. Киләчәктә дә яхшылык яманлыкны җиңсен, күк йөзебез, киләчәгебез тыныч булсын иде.

**Камаева Ләйлә 9 нчы сыйныф**

## Без җаваплы!

Без, 5 нче сыйныф укучылары, гыйнвар аеннан сыйныфыбыз чисталыгы өчен җавап бирәбез. Сыйныф идәннәрен үзебез юабыз, тактаны сөртеп киләсе уку көненә әзерләп калдырабыз. Гөлләргә су сибү, чисталык-пөхтәлекне саклау – безнең бурыч. Эш кешене бизи дип, без бик шатланып бу вазифаны өстебезгә алдык.

**Фазуллин Раяз, сыйныф старостасы.**

## Бер рәхмәт мең бәладән коткарыр

Кышкы каникуллар үтеп, без янәдән мәктәпкә укырга килдек. Каникулда җыйган көч белән яңа белем тупларга җиң сызганып тотындык.

Кыш үзенекен итә, соңгы вакытта көчле бураннар булды. Хәтта укырга да бармадык, өйдә көне буе кар көрәдек.

Беркөнне тәрбия сәгатендә Алия апаның бер яхшылык эшләп аласыгыз киләме дию булды, барыбызда: “Әйе!” дип җавап бирдек һәм дәрестән соң олы яшьтә булган, өстәвенә авыр операция кичергән Зөбәрҗәт апага булышырга киттек.

Капка төбен трактор белән эттерсә дә, ишек алдында кар диңгез кебек җәелеп ята иде.

Без килгәнне күргәч, Зөбәрҗәт апа шундый сөенде, тиз генә көрәкләр табып бирде. Эшләгәндә кем балалары булуыбызны сорады. Мактап карап торды. Бергә эшләве күңелле булды. Ранис белән Ильяс иң калын итеп салган җирдән карны арт якка ташыдылар, ә Лилия белән мин һәм апа чистартып бардык. Ишегалды биерлек булды.

Саф һавада сыйныфташлар белән эшләү - үзе бер рәхәт. Битләребез алсуланды. Истәлек өчен фотога да төштек әле.

Зөбәрҗәт апа: ”Бер рәхмәт мең бәладән коткарыр, балалар”, - дип, әйбәт кенә укуыбызны теләп калды.

**Галимҗанова Әдилә, 7 нче сыйныф.**



## Минем яраткан шөгылем.

Мин быел мәктәпкә беренче класска укырга кердем. Шулай ук Әтнә балалар сәнгать мәктәбенең баян классында укыйм. Минем балалар бакчасына йөргәндә үк, баянда уйнарга өйрәнәсем килә иде. Баянда уйнарга укытучым Рамил Ренат улы өйрәтә. Без аның белән ноталар, көйләр өйрәнәбез. Мин “Хәтирә”, ”Маленькая полька”, “Маленькая елочка” көйләрен баянда уйный беләм. Әти белән әни миңа туган көнгә баян бүләк иттеләр. Бу бүләк өчен мин бик сөендем. Хәзер өйдә буш вакыттым булганда, мин гел баянда уйныйм.

Сәнгать мәктәбенә, баян дәресенә, мин атнага ике тапкыр барам. Миңа бу дәресләр бик ошый. Баянда уйнау минем иң яраткан шөгылем.

**Галявиев Раниль, 1 нче сыйныф**



## "Сәхнәдәшләр" сәхнәдә

Сабакташлар белән үткәрелгән вакыт гел рәхәт хатирәләр белән истә кала ул. Алар белән вакытның узганын да сизмисең. Сизү ген мени, әйтерсең ул каядыр чаба. Чапкан саен артыннан куып тоту авырлаша, үткәнне кирегә әйләндереп, аның мизгелләрен яңадан кичереп булмый. Ә менә хатирәләр белән баетылган истәлекләрне сагынып сөйләп була. Күптән түгел сыйныф җитәкчебез безне чираттагы сәяхәткә алып чыкты. Мәктәпнең тәүге кат бусагасын атлап кергәннән бирле, шундый кызыклы сәяхәтләрдә без, сүз уңаеннан. Бу юлы Әтнә дәүләт драма театры бинасына, "Сәхнәдәш" театр коллективының чираттагы театр тамашасын карарга бардык. Әлеге театр коллективында безнең сабакташыбыз Алия Галәвиева да күп еллар дәвамында йөрүен дәвам итә. Әйткәнемчә, без аны үзебезнең сабакташыбыз итеп күреп өйрәнгән, әмма ул җан өргән рольдә, бөтенләй башка яктан ачылды күк. " Аяз һәм Тылсымлы китап" исемле әсәрне "Сәхнәдәшләр" бик оста итеп уйнадылар. Аларның театрны шулай үз итүләрендә, җитәкчеләре Финә апа Сафиуллинаның тырышлыгы бинихая зур. Әсәре дә безнең якын көнкүрешне яктырткан проблемаларга чишелеш эзләү. Сезнең дә чишелешне табасыгыз килсә, һичшиксез әлеге тамашаны барып күрегез дияр идем. Безне шулай һәрдаим дөнья яңалыклары белән якыннан таныштыру нисбәтеннән, кызыклы һәм үзенчәлекле сәяхәтләр белән тулыландырып, мәктәп тормышына яңа бер сулыш өрүче мөгаллимәбез Гөлназ Рәхиман кызына зур рәхмәтебез һәм хөрмәтебез!

**Хәкимов Әсхәт, 4 нче сыйныф**

## Хәрәкәттә бәрәкәт

Туган ягыбызга ак карлы салкын кыш килде. Быел кар бигрәк куп яуды.

Без физкультура дәресләрендә чаңгы шуабыз. Битләребез суыктан алсулана. Егылып та алабыз, ләкин еламыйбыз . ”Хәрәкәттә –бәрәкәт”,- ди безгә апабыз. Дөрестән дә, саф һавада чаңгы шуу бик рәхәт тә, сәламәтлек очен файдалы да.

**Хәкимов Риназ, 2 нче сыйныф**

## Кыш

Салкын җилләре исеп

Килде салкын кыш,ай-яй!

Кышны сагынган балалар

Тәгәрәтте кар бабай.

**Юсупова Динә, 2 нче сыйныф**

## Минем акыллы песием

Минем бик матур , бик акыллы ике песием бар.



Берсенең исеме - Ласка. Мин аңа бик ягымлы булганы өчен шундый кушамат бирдем. Аның йоны аклы-сарылы. Күзләре яшел. Ул минем мәктәптән кайтканымны сагынып көтеп тора. Мин кайткач мияулый һәм өстемә менә. Ул бик тәртипле дә . Теләсә кая менми, әйберләрне пычратмый. Өйгә тычканнар да кертми, бик шәп сакчы ул.

Мин песиемне бик яратам.

**Харасов Әмир, 3 сыйныф**

## Настоящие друзья.

Жили два друга Ваня и Гриша. У Гриши был очень красивый самосвал, а у Вани нет. Ваня тоже хотел машину.

Но у его родителей не было денег. Поэтому Ваня дружил с Гришей, чтобы играть с самосвалом. А Гриша этого не знал, он думал , что они настоящие друзья.

Однажды, они возвращались домой, им пришлось проходить мост. Гриша споткнулся и упал с моста, он сам удержался, а самосвал утонул. Он крикнул Ване “помоги мне”, а Ваня сказал, что раз у него теперь самосвала нет, то он с ним не дружит. И ушел.

Мимо проходил Сёма. Он увидел Гришу и вытащил его. Теперь они дружат.

**Низомов Джамшит, 3 класс.**

